**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МОНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

От 03.08.2020 года № 152

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монаш авыл җирлегенең
«Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монаш авыл җирлеге территорияләрен
төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында»
2019 елның 20 февралендәге
69 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 5 июнендәге 78 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Түбәндәге эчтәлекле X бүлеген өстәргә:

«X. Җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар.

211. Җир кишәрлекләренә хокукчылар үзләренең милкендәге, биләгән яисә файдаланган җир кишәрлекләрен Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар үткәрергә тиеш.

212. Сосновский балтырганын юк итү буенча чаралар аның чәчәккә бөреләнгәнче һәм чәчәк ата башлаганчы үткәрелергә тиеш.

213. Сосновский балтырганыннан арындыру буенча чаралар түбәндәге ысуллар белән үткәрелергә тиеш:

химик - гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар белән үсеш учакларын сиптерү;

механик - чабу, коры үсемлекләрне урып-җыю, тамырларын алып ату;

агротехник - туфрак эшкәртү, күпьеллык үләннәр чәчү.»

2. Әлеге карарны «Менделеевск яңалыклары» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Норматив документлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монаш авыл җирлегенең законлылыкны, хокук тәртибен саклау буенча Советына йөкләргә.

Монаш авыл җирлеге Советы Рәисе Иосифов Р.Ф.